МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.02.2022 г.Казань № 102

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 16 мартында 8960 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 санлы боерыгы белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 санлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.08.2016 №465, 14.05.2018 №363, 10.10.2018 №935, 22.01.2019 №45, 03.04.2019 №226, 05.08.2019 №595, 23.10.2019 №888, 14.07.2020 №514, 28.09.2020 №680, 08.09.2021 №645 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Н.Б.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 14 фералендә № 102 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 санлы боерыгы белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.2 пункттагы өченче кызыл юлны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4 пунктын өстәргә:

«2.4.4. Гражданинны юллама алу өчен исәпкә кую яки исәпкә куюдан баш тарту турында карар кабул итү чоры, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган белешмәләр алынмаган очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

2.5.1 пунктының дүртенче, бишенче кызыл юллары, 2.5.7 пунктының өченче-бишенче кызыл юллары, 2.5.8, 2.5.10, 2.5.11 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга;

2.6.1 пунктта:

җиденче кызыл юлда «исәпләгәндә» сүзен «санап чыгарганда» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы-уникенче кызыл юлларын үз көчен югалткан дип танырга;

2.7.1 пунктын үзгәртеп, түбәндәгечә бирергә:

«2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны тулы булмаган күләмдә тапшырылуы;

әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән документларны гамәлдә булу чоры узган хәлдә тапшыру;

документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве;

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, төп документларның күрсәтелмәве;

документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

гаризаның гражданнарга юлламалар бирергә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылуы.»;

2.7.2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2.8.2 пунктының җиденче кызыл юлында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча» сүзләрен «салымнар, җыемнар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

2.8.3 пункты, 2.15.1 пунктының алтынчы кызыл юлын, 2.15.2 пунктының дүртенче, тугызынчы кызыл юлларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.16 пунктны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә: «Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге гамәлгә ашырылмаган.»;

3 нче бүлектә:

3.3.1.1, 3.3.1.2, 3.3.1.3 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктта:

дүртенче кызыл юлда «яисә гаризаны теркәү турындагы белдерүне мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетына яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрү (гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта)» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче кызыл юлда «Гаризаны Бердәм портал яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче һәм сигезенче кызыл юлларда «, Бердәм портал аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки «Интернет» челтәре аша» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.1 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәре турында;»;

түбәндәге эчтәлекле тугызынчы һәм унынчы кызыл юллар өстәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.»

3.4.2 пунктта:

сигезенче кызыл юлны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«гражданинның уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәре турында;»;

унынчы-уникенче кызыл юлларын үз көчен югалткан дип танырга;

3.4.3 пунктта «3.4.2 пунктчасының» сүзләрен «3.4.2 пунктының» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.1 пунктта:

алтынчы кызыл юлны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләр законнарда билгеләнгән чорда алынмаган очракта, әлеге пунктта билгеләнә торган процедураларны гамәлгә ашыру чоры 20 эш көненә озайтыла. Бу очракта әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар ведомствоара хезмәттәшлек

кысаларында соралган белешмәләр алынган  көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле җиденче кызыл юл өстәргә:

Процедураның нәтиҗәсе: ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында карар проекты, ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә  кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында карар кабул итү вакытын озайту турында белдерү.»;

3.6 пунктта:

өченче кызыл юлда «яисә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында белдерүне мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетына, яки мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына юллау юлы белән)» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче кызыл юлда «, ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында кабул ителгән карар хакындагы хәбәрне мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетына, яки мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7.1 пунктының бишенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.»;

3.7.3 пунктның беренче кызыл юлында «,  электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша» сүзләрен төшереп калдырырга.